| ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ |
|---|---|---|

№ 53

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«29» мая 2014 ел

**Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 2012 елның 23 гыйнварыннан № 3 "Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" боерыгына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 2012 елның 23 гыйнварыннан № 3 "Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" боерыгы белән расланган Регламентны (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2012 елның 5 апрелендә теркәлгән, теркәлү номеры - 1466, "Республика Татарстан", 2012 елның 14 апреле, № 73) Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексына, 2010 елның 27 июленнән № 210 – ФЗ Федераль законга һәм 2012 елның 7 маеннан № 601 "Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында" Россия Федерациясе Президенты Указының 1 пунктындагы "д" пункт өлешенә ярашлы итү максатларында

**Б О Е Р Ы К Б И Р Ә М:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 2012 елның 23 гыйнварыннан № 3 "Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" боерыгына (алга таба - Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның икенче абзацында һәм 7 пунктның беренче абзацында "техник регламентларның" сүзләре артыннан "(нормаларның һәм кагыйдәләрнең), бүтән норматив-хокукый актларның" сүзләрен төшереп калдырырга;

аталган боерык белән расланган Регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

аталышында, текст һәм Регламентның кушымталарында "техник регламентларның" сүзләреннән соң "(нормаларның һәм кагыйдәләрнең), бүтән норматив-хокукый актларның" сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4 пунктына бишенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"2012 елның 7 маеннан № 601 "Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында" Россия Федерациясе Президенты Указы белән (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2012, № 19, 2338 ст);";

Регламентның 2 бүлегендәге 2.12 пунктның беренче абзацында "30 минут" сүзләрен "15 минут" сүзләре белән алмаштырырга;

Регламентның 2 бүлегендәге 2.12 пунктның икенче абзацында “40 минут” сүзләрен “15 минут” сүзләре белән алмаштырырга;

2.15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:

1) документларны кабул итүнең һәм карауның вакытларын саклау;

2) дәүләт хезмәтен алу нәтиҗәләре вакытын саклау;

3) дәүләт хезмәткәре тарафыннан кылынган Административ регламент бозулар буенча прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булу;

Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең мөмкин булу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:

1) кабул итү алып барылган, документлар бирелә торган биналарның җәмәгать транспортына якын булган зонада урнашуы;

2) белгечләрнең, һәм шулай ук гаризачылардан документларны кабул итү башкарыла торган биналарның  тиешле күләмдә булуы;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, “Интернет” челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында тулы мәгълүмат булу;”;

3 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Административ процедураларны үтәүнең составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны башкару тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада башкару үзенчәлекләре, һәм шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә башкару үзенчәлекләре”;

3.2 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Инспекциянең территориаль органының Төзелеше төгәлләнгән объектларның документларын кабул итү тәртибен күзәтү бүлеге белгече гаризачыны, шул исәптән тапшырылучы документларның составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтен алу буенча башка мәсьәләләрдә консультацияли һәм шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны рәсмиләштерүдә ярдәм итә”;

3.3.1 пунктының беренче абзацында “электрон рәвештә” сүзләреннән соң “Инспекциянең сайтыннан файдаланып” сүзләрен өстәргә;

3 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 3.3.10 пункты белән тулыландырырга:

“3.3.10. Ярашлылык буенча бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәтү каралмаган (башкарылмый).”;

4 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 4.4 пункты белән тулыландырырга:

“4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольдә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алганда һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлегендә Инспекциянең ачык эшчәнлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла”;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“**5. Вазыйфаи затның гамәлләрен (гамьсезлеген), һәм шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәткәндә аның тарафыннан кабул ителүче карарны судка кадәр (судтан гайре) шикаять кылу тәртибе**

5.1.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Инспекциядәге вазыйфаи затның, яки Инспекциядәге дәүләт хезмәткәренең гамәлләрен (гамьсезлеген) *судка кадәрге тәртиптә* Инспекциягә шикаять кылу хокукына ия. Инспекция башлыгының (Инспекция башлыгы урынбасарының) дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле кабул ителгән карарлары буенча шикаять Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетына тапшырыла.

Гаризачы шикаять белән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) гаризачы тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү турында тапшырылган соратып алу гаризасын теркәү вакыты бозылу;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылу;

3) гаризачыдан дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары белән, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары белән каралмаган документларны таләп итү;

4) гаризачыдан аларны тапшыру Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары белән, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту, әгәр дә баш тарту өчен нигезләр Россия Федерациясе федераль законнары һәм алар нигезендә кабул ителгән норматив-хокукый актлар, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары белән каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәтен күрсәткән вакытта гаризачыдан Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары белән, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары белән каралмаган түләү таләп итү;

7) дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, органдагы дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи затның дәүләт хезмәтен күрсәткән вакытта бирелгән документлардагы хаталарны һәм төгәлсезлекләрне төзәтүдән баш тартуы яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытлары бозылу.

5.1.2. Шикаять шәхси кабул итү барышында гаризачының шәхсән үзе тарафыннан бирелергә, почта буенча, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәк аша, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең рәсми сайты (http://gsn.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru) яки республиканың дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша юлланырга мөмкин.

5.1.3. Инспекциягә кергән шикаять шикаятьләрне карау вәкаләтләре белән вәкаләтләнгән вазыйфаи зат тарафыннан аны теркәгәннән соң 15 эш көне дәвамында каралырга тиеш, ә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Инспекциянең, Инспекциядәге вазыйфаи затның гаризачыдан документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм төгәлсезлекләрне төзәтүдән баш тартуын шикаять иткән очракта яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән вакыты бозылуны шикаять иткән очракта – аны теркәгәннән соң биш эш көне дәвамында.

5.1.4. Шикаять түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, органның карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлекләре) шикаять кылынучы дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гаризачы – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, гаризачы – юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, һәм шулай ук гаризачыга җавап бирү өчен элемтә телефонының номеры (номерлары), (булган очракта) электрон почта һәм почта адресы (адреслары);

3) дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, органдагы дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи затның яки дәүләт хезмәткәренең шикаять кылына торган карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлекләре) турында белешмәләр;

4) алар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, органның дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлекләре) белән килешмәве буенча гаризачы тарафыннан китерелгән дәлилләр.

5.1.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгәннәрне раслаучы документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Ул очракта шикаятьтә аңа теркәлүче документларның исемлеге китерелә.

5.1.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Инспекция башлыгы (Инспекция башлыгы урынбасары) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүче Инспекция тарафыннан кабул ителгән карарны кире кагу, җибәрелгән хаталарны төзәтү, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм җитешсезлекләрне төзәтү, аларны алу Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары белән каралмаган акча чараларын гаризачыга кайтарып бирү формасында, һәм шулай ук бүтән формаларда канәгатьләндерә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.1.6. пункт өлешендә күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча гаризачыга язмача формада һәм гаризачының ихтыяры белән электрон формада шикаятьне карау буенча мотивлаштырылган җавап юллана.

5.1.7. Шикаятьне карау барышында һәм нәтиҗәсендә административ хокук бозылу яисә җинаять кылыну билгеләре ачыкланса, шикаятьне карау вәкаләтләре белән вәкаләтләнгән вазыйфаи зат кичекмәстән бар булган материалларны прокуратура органнарына юллый.”.

2. Регламентка карата кушымталарның тексты буенча “төзекләндерелгән”, “капиталь төзекләндерү” сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Юридик бүлек башлыгына (Р.З. Фатыйховка) әлеге боерыкны дәүләт теркәве өчен Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына юлларга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башлык В.А. Кудряшов